# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Исәнсеф авыл җирлеге Татар Бүләре торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

21 ноябрь 2024 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2024 елның 24 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлеге Татар Бүләре торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йөз) сум күләмендә билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

**1.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү**

1) янгын сүндерү техникасын тоту
2) гидрант урнаштыру
3) пирсны җайлаштыру

**2. Урам яктырту җайланмалары, ремонт:**

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү
2) материаллар, светодиод лампалар сатып алу

**3. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге:**

1) кышкы чорда юлларны карап тоту
2) җәйге чорда юлларны карап тоту
3) юлны ремонтлау, материаллар сатып алу
4) урамнарны грейдирлау
5) юл кырындагы үләнне чабу, кардан чистарту
6) юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру

**4. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:**

1) Бөек Ватан сугышы обелискын ремонтлау, территорияне төзекләндерү.

**5. Яр буе зоналарын, сулыкларны төзекләндерү һәм чистарту:**

1) «Сикия» елгасының кушылдыгын төзекләндерү һәм чистарту

**6. Традицион күмү урыннарын карап тоту:**

1) каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) зират территориясендә үлән чабу
3) карт агачларны кисү
4) койма-киртәләрне ремонтлау

**7.Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**

1) су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү
2) су системасында агымдагы ремонт эшләре

**8. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:**

1) массакүләм чаралар урынын төзекләндерү
2) материаллар сатып алу, «Сабантуй»паркын төзекләндерү
3) халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу

Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә.».

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 194 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 120, бу 62% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
Гражданнар җыенында катнашкан 102 кеше «РИЗА» позициясе өчен,
18 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Татар Буләре торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Сораулар буенча карар кабул итәргә:
"2024 елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең Татар Бүләре торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000,00 (бер мең) сум күләмендә, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфгангстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга, көндезге бүлектә укучы студентларга 500,00 (биш йоз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә. Луганск һәм Донецк халык Республикаларында махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән гражданнарны, хатынын (ирен), балигъ булган балаларын, ә алар булмаган очракта, ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итәргә. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

**1.Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү**

1) янгын сүндерү техникасын тоту
2) гидрант урнаштыру
3) пирсны җайлаштыру

**2. Урам яктырту җайланмалары, ремонт:**

1) урам яктырту челтәрләрен ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү

2) материаллар, светодиод лампалар сатып алу

**3. Торак пунктлар чикләрендә юл эшчәнлеге:**

1) кышкы чорда юлларны карап тоту
2) җәйге чорда юлларны карап тоту
3) юлны ремонтлау, материаллар сатып алу
4) урамнарны грейдирлау
5) юл кырындагы үләнне чабу, кардан чистарту
6) юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру

**4. Һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү:**

1) Бөек Ватан сугышы обелискын ремонтлау, территорияне төзекләндерү.

**5. Яр буе зоналарын, сулыкларны төзекләндерү һәм чистарту:**

1) «Сикия» елгасының кушылдыгын төзекләндерү һәм чистарту

**6. Традицион күмү урыннарын карап тоту:**

1) каты коммуналь калдыкларны чыгарту
2) зират территориясендә үлән чабу
3) карт агачларны кисү
4) койма-киртәләрне ремонтлау

**7.Су белән тәэмин итү һәм су җибәрү системаларын, су башнясын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуын һәм халыкка су бирүне тәэмин итү:**

1) су башнясын ремонтлау, һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү
2) су системасында агымдагы ремонт эшләре

**8. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру:**

1) массакүләм чаралар урынын төзекләндерү
2) материаллар сатып алу, «Сабантуй»паркын төзекләндерү
3) халыкның күпләп ял итү территорияләрендә үлән чабу”-

**КАБУЛ ИТЕЛДЕ**

3. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең җыен узган урындагы мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Исәнсеф авыл җирлегенең рәсми http://muslumovo.tatarstan.ru сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены рәисе, Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районының Исәнсеф
авыл җирлеге башлыгы И.А.Салихов